КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2026 ел, 25 май г.Казань № б-1070

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 4 июнь, б-1185 номерлы боерыгына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 18 февраль, 102 нче карары; Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 6 май, б-912 нче; 2017 ел, 21 июнь, б-1379 нчы; 2017 ел, 22 сентябрь, б-2390 нчы; 2019 ел, 21 декабрь, б-3330 нчы; 2022 ел, 9 март, б-470 нче; 2023 ел, 2 март, б-540 нчы боерыклары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктның икенче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

әлеге боерык белән расланган «Казан талантлар ачык университеты 2.0» автоном коммерциягә карамаган оешмасы идарәсе составын яңа редакциядә (боерыкка теркәлә) бәян итәргә.

2. Түбәндәгеләр үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 21 июнь, б-1379 нчы боерыгы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 21 декабрь, б-3330 нчы боерыгының икенче – унынчы абзацлары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 9 март, б-470 нче боерыгы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 2 март, б-540 нчы боерыгы.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 4 июнь, б-1185 нче
боерыгы белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2026 ел, 25 май, б-1070 нче
боерыгы редакциясендә)

«Казан талантлар ачык университеты 2.0»
автоном коммерциягә карамаган оешмасы идарәсе
составы

| | |
|---|---|
| Фазлыева Ләйлә Ринат кызы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, идарә рәисе |
| Әхмәдиева Алинә Рәфикъ кызы | Татарстан Республикасы Рәисенең Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты җитәкчесе урынбасары – иҗтимагый проектлар бүлеге мөдире, идарә рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Мөҗипов Рәмис Гаптрәис улы | Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрының беренче урынбасары, идарә рәисе урынбасары |
| Әдһәмова Юлия Илдар кызы | Татарстан Республикасы мәдәният министрының беренче урынбасары |
| Әхмәтова Әдилә Марат кызы | «Казан талантлар ачык университеты 2.0» автоном коммерциягә карамаган оешмасының башкарма директоры (килешү буенча) |
| Выборнов Андрей Андреевич | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының югары, урта һөнәри белем бирү һәм фән бүлеге башлыгы |
| Габдрахманов Булат Фәнил улы | Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министры урынбасары |
| Галиев Артур Ирек улы | Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрының беренче урынбасары |
| Галиев Инсаф Мөшәрраф улы | Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгы җитәкчесенең беренче урынбасары |

| | |
|---|---|
| Кадыйров Азат Рифгать улы | Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министры |
| Карпов Родион Михайлович | Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министрының беренче урынбасары |
| Шәйхетдинов Хәлил Хәмит улы | Татарстан Республикасы спорт министрының беренче урынбасары |